КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1281

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 сентябрь, 873 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 сентябрь, 873 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашуга бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашуга бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашуга бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендәге чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели) (алга таба – субсидияләр, чаралар).»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен үткәрелә торган бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында бирелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин